| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 май № 293

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 20 февраль, 102 нче карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 20 февраль, 102 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктның өченче абзацына «, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, проект документларының дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган капиталь төзелеш объектының модификацияләнгән проект документларына мөнәсәбәтле бәяләмә бирүне, капиталь төзелеш объектларын төзү, төзекләндерү һәм капиталь ремонтлауның смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне, проект документларына аудитны» сүзләрен өстәргә.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешләре Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләүнең дөреслегенә тикшерү үткәрү тәртибе турында» 2014 ел, 9 декабрь, 963 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы карарының 12 нче пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\293.doc